Шулай да була

# АЛЛАҺЫ ТЕЛӘСӘ, ДИП ӘЙТ

Бу хикәядә сүз революция чорында, бик тынычсыз заманда, кайбер кешеләрне нигә кулга алуларын да аңлатмыйча, алып китеп, юк итә торган вакытта хатын белән ир арасында булган хәл турында.

Кышның иң озын төннәренең берсендә, бер абыйның хатыны коймак пешергәндә:

- Хәзер чәй эчеп, коймак ашарбыз, - дип әйтеп куя ире. Иренең мондый сүзләрне әйтүен ишетеп, хатын:

- Аллаһ теләсә, дип әйт, юләр - дип әйтә.

- Аллаһ теләсә дә, теләмәсә дә коймак инде пешеп җитә, ашыйм мин аны барыбер. Аллаһ теләсә, дигән сүз белән генә берәр нәрсә үзгәрергә мөмкинме? - ди ире.

- Динсезләр сүзе сөйләп, йорттагы бәрәкәтне бетереп утырма, - дип җавап бирә хатыны. Коймак пешеп бетеп, өстәлгә куйган вакытта кинәт эт өрүе ишетелә. Хатын урамга чыгып, “кем бар анда?” дип сорый.

- Ирең киенсен аның артыннан килдек, - дигән тавыш яңгырый.

Эт өрдереп, иренең киенеп чыгуын таләп итүчеләр, дәүләт органнары тарафыннан килгән кешеләр була. Ире кулына алган коймагын да кире куеп, аны алырга килгән кешеләр белән китеп бара.

Шулай итеп берничә атна узып китә. Бер көнне хатын ишек кагуны ишетә. Этнең дә өрмәвенә сәерсенеп, ишекне ачыр алдыннан:

- Кем анда? - дип сорый ул. Ишек кагучы кеше аның ире була.

- Аллаһ теләсә, иншаллаһ, бу синең ирең, - дип җавап кайтара ире. “Нигә сине сәбәпсез алып киттеләр?” дигән сорауга да: “Минe башка бер кеше белән бутаганнар. Тикшерделәр һәм өйгә кайтарып җибәрделәр”, дип кенә җавап бирә.

Хөрмәтле дустым! Ни гаҗәп, дөнья йортында яшәүче бик күп кешеләр, кулларында теләкләреннән башка әйбер юк икәнлеген белмиләр. Белсәләр дә, еш кына онытып җибәрәләр. Кеше наданлыгы аркасында, кулында булган бөтен әйберне үзлегеннән бар булган, дип уйлый. Әйтерсең, гәүдәсен, тәнен, гәүдәсендәге бөтен әгъзаларын хәрәкәт иттерүче көчен, яхшы якка юнәлдерә торган акылын, зирәклеген, башкаларны җәлеп итә торган чибәрлеген үзе бар итеп тапкан, дип саный. Югарыда әйтеп үткән бөтен әйберләр Аллаһ тарафыннан кешегә насыйп ителгәннәр. Кеше “мин, минеке”, дигән наданлыгы сәбәпле шуны аңламый. Ул Аллаһ биргән бөтен әгъзалары һәм акыл - зирәклеге белән хәрәкәт итә. Ниндидер дәрәҗәләргә ирешеп, мал иясе булып китә. Һәм дөньяда барлыкка килгән дәрәҗәсен, малын үзеннән килгән, дип уйлый.

Тар фикерле, наданлык чокырына төшеп киткән бу бәндәләрнең колагына бер сүз әйтәсе килә. Аллаһ бирсә - бирә, бирмәсә - бирми. Һәм булган әйбереңне дә бер мизгелдә кулыңнан тартып алырга мөмкин. Күрмисеңме, синең тирәндә күпме кешеләр бар. Алар кичә генә шапырынып дөньяның өстен - аска китереп, чабып йөри иделәр. Ә инде бүген аяксыз калып, урын өстендә хәрәкәтсез булып яталар. Әле кичә генә “мин йорт салдым, машина алдым, гаиләмне ашатам”, дигән кешеләр кашык күтәреп, авызларына бер йотым су каба алмыйлар. Алар үлмәсен өчен, янындагы якыннары авызларын ачтырып су салалар.

Әй, син, “Мин, минеке”, дигән кеше! Кичә генә синең белән елмаешып, сөйләшеп утырган бәндәнең телсез калуын бер дә күргәнең юкмы? Кичә генә күзе булган кешенең бер мизгелдә күзсез калганын әллә күзәткәнең юкмы? Мондый кешеләрне күргәнең, ишеткәнең булмаса, бар сукырлар, юләрләр, телсезләр, чукраклар йортларына, күр телсез - чукракларны, бөтен җире сәламәт булса да, акылын югалтып, юләрләр йортына эләгүчеләрне. Уйлама, бу бәндәләрнең авыр кичерешләре үз теләкләре белән барлыкка килгән, дип. Акыллы кеше Аллаһ биргән акыл, көч - куәте һәм теләге белән дөньяда хәрәкәт итеп яшәргә һәм бөтен нәрсә, Аллаһы рөхсәт итсә һәм теләсә генә барлыкка килгәнен яхшы белергә тиеш.

Бакчасында уңыш күрергә теләгән кеше орлыкларны туфракка чәчә. Әмма ул орлыклардан җимешләр барлыкка килү тулысынча Аллаһ кулында. Дөньяда шундый үрнәкләр дә күрергә мөмкин. Аллаһ теләмәсә, уңышлы итеп пешкән җимешләр дә, җыеп алганнан соң адәм баласына насыйп булмыйча, бик тиз череп. юкка чыга.

Әй, сөекле дустым! Шуны бел һәм онытма: синдә һәм кулыңда булган бөтен әйберләрең, хәттә теләгеңнең тормышка ашуы да - бөтенесе Аллаһының кулында. Тормышыңда бик күп тормыш үрнәкләрең бар. Кайбер әйберләрне бик теләдең, әмма килеп чыкмады. Кайберләрен бөтенләй уйламадың, әмма алар синең тормыш юлыңда каршыңа ук чыгып басты. Шуңа күрә нәрсә генә эшләргә теләсәң дә, “Аллаһ теләсә”, дигән сүз иң беренче булсын күңелеңдә. Бу сүзне бер дә өзмә син телеңнән.

“Һичбер нәрсә турында әйтә күрмә: “Мин иртәгә аны эшләрмен”, дип. Әйтә торган булсаң да, “Аллаһы теләсә генә эшләрсен”, дип әйтә күр сүзеңне. Һәм зекер ит, Раббыңны онытkan булсаң.

**Мәхмүт хәзрәт ШӘРӘФЕТДИН.**
***“Бәхетлеләрнең серләре“ китабыннан.***

# Коръән аятьләре

Аллаһ аны (ягъни шайтанны) ләгънәт кылды, һәм ул әйтте: “Мин һичшиксез синең колларыңның билгеләнгән өлешен алырмын! Мин һичшиксез аларны адаштырырмын, аларда буш хыяллар уятырмын, терлекләренең колакларын кисәргә боерырмын һәм Аллаһ барлыкка китергәнне үзгәртергә боерырмын”.

Аллаһ урынына Шайтанны ярдәмче һәм яклаучысы итеп алучы ап-ачык зарарга ирешүчедер. Ул аларга вәгъдәләр бирә һәм аларда өметләр уята. Ә шайтанның вәгъдәсе - фәкать алдау гына. Аларның барачак урыны - Җәһәннәм, һәм алар аннан котылу тапмаслар. *(Коръән, 4:118-121).*

**Зәйнәп ШАҺВӘЛИЕВА,**
**6нчы сыйныф укучысы**

**КАУРЫЙ КАЛӘМ**

*Барлык галәмнәрне яралтучы*
*Аллаһыга мактау, сәламнәр!*
*Бу дөньяда нигә килгәннәрен*
*Белсә иде Җирдә адәмнәр.*
*Дөнья куып, байлык җыя халык;*
*Төзи алар зур-зур биналар.*
*Тик, кызганыч, олуг Раббыбызны*
*Ахыр чиктә искә алалар.*
*Адәм белән җеннәрне бит Аллаһ*
*Сәҗдә кылыр өчен яралткан.*

*Нәрсә ашап, ничек яшәргә дә*
*Коръән китабында аңлаткан.*
*Авырмыни сәҗдә кылып, аннан*
*Хак Тәгаләбезгә сыену.*
*Һидаятьле, туры юлдан барып,*
*Хәрәм-гөнаһлардан тыелу.*
*Гаурәт каплап йөрүне дә*
*Безгә Аллаһыбыз боерган.*
*Зина кылу, хәрәм ашаулар -*
*Болар барсы да тыелган.*
*Чистартынып, намаз укулар*
*Беркемгә һич киртә түгел.*
*Тормышым чишмәдәй аксын*
*дисәң,*
*Коръән-Кәримгә ябыш бүген!*



## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Рәжәб-Шәғбан 2012 миләди йыл**
**1433 һижри йыл.**

| Рәжәб, Шәғбан | Аҙна көндәре | Май, Июнь | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сыға | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6 | Кесе йома | 16 | 4.40 | 6.10 | 14.30 | 20.45 | 22.15 | 23.45 |
| 7 | Йома | 17 | 4.38 | 6.08 | 14.30 | 20.47 | 22.17 | 23.47 |
| 8 | Шәмбе | 18 | 4.37 | 6.07 | 14.30 | 20.49 | 22.19 | 23.49 |
| 9 | Йәкшәмбе | 19 | 4.35 | 6.05 | 14.30 | 20.51 | 22.21 | 23.51 |
| 10 | Дүшәмбе | 20 | 4.34 | 6.04 | 14.30 | 20.52 | 22.22 | 23.52 |
| 11 | Шишәмбе | 21 | 4.32 | 6.02 | 14.30 | 20.54 | 22.24 | 23.54 |
| 12 | Шаршамбы | 22 | 4.31 | 6.01 | 14.30 | 20.55 | 22.25 | 23.55 |
| 13 | Кесе йома | 23 | 4.29 | 5.59 | 14.30 | 20.57 | 22.27 | 23.57 |
| 14 | Йома | 24 | 4.28 | 5.58 | 14.30 | 20.58 | 22.28 | 23.58 |
| 15 | Шәмбе | 25 | 4.26 | 5.56 | 14.30 | 21.002 | 22.30 | 00.00 |
| 16 | Йәкшәмбе | 26 | 4.25 | 5.55 | 14.30 | 1.01 | 22.31 | 00.01 |
| 17 | Дүшәмбе | 27 | 4.24 | 5.54 | 14.30 | 21.03 | 22.33 | 00.03 |
| 18 | Шишәмбе | 28 | 4.23 | 5.53 | 14.30 | 21.04 | 22.34 | 00.04 |
| 19 | Шаршамбы | 29 | 4.22 | 5.52 | 14.30 | 21.06 | 22.36 | 00.06 |
| 20 | Кесе йома | 30 | 4.20 | 5.50 | 14.30 | 21.07 | 22.37 | 00.07 |
| 21 | Йома | 1 | 4.19 | 5.49 | 14.30 | 21.08 | 22.38 | 00.08 |
| 22 | Шәмбе | 2 | 4.18 | 5.48 | 14.30 | 21.10 | 22.40 | 00.10 |
| 23 | Йәкшәмбе | 3 | 4.18 | 5.48 | 14.30 | 21.11 | 22.41 | 00.11 |
| 24 | Дүшәмбе | 4 | 4.17 | 5.47 | 14.30 | 21.12 | 22.42 | 00.12 |
| 25 | Шишәмбе | 5 | 4.16 | 5.46 | 14.30 | 21.13 | 22.43 | 00.13 |
| 26 | Шаршамбы | 6 | 4.15 | 5.45 | 14.30 | 21.14 | 22.44 | 00.14 |
| 27 | Кесе йома | 7 | 4.14 | 5.44 | 14.30 | 21.15 | 22.45 | 00.15 |
| 28 | Йома | 8 | 4.14 | 5.44 | 14.30 | 21.16 | 22.46 | 00.16 |
| 29 | Шәмбе | 9 | 4.13 | 5.43 | 14.30 | 21.17 | 22.47 | 00.17 |
| 30 | Йәкшәмбе | 10 | 4.12 | 5.42 | 14.30 | 21.18 | 22.48 | 00.18 |
| 1 | Дүшәмбе | 11 | 4.12 | 5.42 | 14.30 | 21.19 | 22.49 | 00.19 |
| 2 | Шишәмбе | 12 | 4.12 | 5.42 | 14.30 | 21.20 | 22.50 | 00.20 |
| 3 | Шаршамбы | 13 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.20 | 22.50 | 00.20 |
| 4 | Кесе йома | 14 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.21 | 22.51 | 00.21 |
| 5 | Йома | 15 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.22 | 22.52 | 00.22 |
| 6 | Шәмбе | 16 | 4.10 | 5.40 | 14.30 | 21.22 | 22.52 | 00.22 |

# НАМАЗ УКЫРГА ӨЙРӘНҮ

Намазның тышкы шартлары:

1) Гөселле булу,
2) Тәһарәтле булу.
3) Киемең пакь булу.
4) Намаз укый торган урын пакъ булу.
5) Гаурәт җирләре капланган булу (Ирләргә кендектән алып тезләргә кадәр, ә хатын-кызларның, йөзләреннән һәм беләзеккә кадәр кулларыннан тыш, бөтен гәүдәсе гаурәт булып санала).
6) Намаз вакыты кергән булу, (календарьларда аның төгәл вакыты курсәтелгән).
7) Кыйбла тарафына юнәлү. (Мәккә шәһәрендәге кәгъбәтуллаһ). Рәсәй өчен бу көньяк.
8) Нинди намаз укыйсыңа ният кылу.

Намазның эчке шартлары:

(Тәкбир) Намазга керешкәндә “Аллаһу әкбәр” дип әйтү.

(Кыйәм) өч аят укыр вакыт басып тору.

(Кыйраәт)

Кыйәмдә өчаят чамасы көрьән уку.

(Рокуг) Кыйәмнән соң иелеп тору.

(Сужуд) Маңгайны җиргә тидереп, ике мәртәбә сәҗдә кылу.

(Кугуд) Намаз ахырында утырып тору.

(Тәртиб) Намазны тәртибе белән уку.

8) (Хуруж) Намаздан уз ихтиярың белән чыгу.

Госел дип авыз һәм борынга су алып чайкау, сеңгерү һәм бөтен тәнне су белән юуны әйтәләр. Госелсез кешегә намаз уку, Коръәнгә кагылу, уку һәм мәчеткә керү тыела.

Госел алу мәҗбүри булган очраклар:

1. Җөнеб булу: а) җенси якынлык кылу;
б) төшләнү (поллюция);
в) мәни киҟн.
2. Хәез каны тәмам булу (менструация)



3. Нифас каны тәмам булу (послеродовые выделения) күбесе (40 көн).

Истинжа: Олы һәм кече хаҗәтләрне үтәгәннән соң су белән әгъзаларны юу. Истинҗасыз тәһарәт һәм госел алынмас.

Тәһарәт алганда түбәндәгеләр эшләнә:

1. 3 мәртәбә беләзеккә кадәр куллар юыла.
2. 3 мәртәбә авыз - борын эче чайкала.
3. 3 мәртәбә бит юыла.
4. куллар терсәккә кадәр (терсәкләрне кертеп) 3 мәртәбә юыла.
5. кулларны юешләтеп башка һәм колакларга мәсих кылына.
6. уңнан башлап, 3 мәртәбә аяклар (тубыкларны кертеп) юыла.

Кеше олы яки кече хәҗәтен утәсә, йокласа яки ирексездән тәненнән: нәжес, кан, эрен, газ, үлек, косык, бәвел, чыкса тәһарәте бозылган санала.

Һәрбер намазның вакыты икенче намаз вакыты керү белән тәмамлана, бары тик иртәнге намаз вакыты гына кояш чыгу белән тәмамлана.

Берәр сәбәп белән намаз утәлми калган очракта, аны каза кылу (кайтарып уку) тиеш.